**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

_____________ № ______

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының район мәдәният йортлары һәм авыл клублары базасында оештырылган гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укыту-консультация пунктларының 2022 елда гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә эшләмәүче халыкка консультация хезмәтләре күрсәтү буенча смотр-конкурсын үткәрү нәтиҗәләре турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.12.2001 ел, № 3029-р боерыгы белән расланган һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы җитәкчесе урынбасары-Татарстан Республикасы Премьер-министрының 01.04.2022 ел, №4 боерыгына таянып, 2022 елга Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү буенча төп чаралар планы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башлыгының 17.05.2002 елгы №6-р боерыгы белән “Укучыларны һәм эшләмәүче халыкны әзерләү өчен гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән яклау буенча укыту-матди базасының смотр-конкурслары турындагы нигезләмәләрне раслау турында" , "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының район мәдәният йортлары һәм авыл клублары базасында оештырылган гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укыту-консультация пунктларының 2022 елда гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә эшләмәүче халыкка консультация хезмәтләре күрсәтү буенча смотр-конкурсын үткәрү турында", 2022 елның маенда гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-консультация пунктлары(алга таба УКП) смотр-конкурсы оештырылды һәм үткәрелде, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының район мәдәният йортлары һәм авыл клублары базасында 2022 елда гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә эшләмәүче халыкка консультацион хезмәт күрсәтү, Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча УКП уку-укыту базасын һәм документациясен тикшерү, конкурс комиссиясе тәкъдим иткән бәяләр таблицалары нигезендә үткәрелгән смотр-конкурс нәтиҗәләре буенча Актаныш районы Башкарма комитеты

**БОЕРА:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының район мәдәният йортлары һәм авыл клублары базасында төзелгән гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча УКП смотр-конкурсында җиңүчеләр итеп түбәндәге призлы урыннарны бирүне танырга:

- 1 урын - Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Актаныш район мәдәният йорты” муниципаль бюджет учреждениесе.
(директор, УКП башлыгы - Вәлиева Г.С.);

- 2 урын - Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Пучы авыл мәдәният йорты” муниципаль бюджет учреждениесе.
(директор, УКП башлыгы -Нуретдинова И.Г.);

- 3 урын - Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Яңа Әлем авыл мәдәният йорты” муниципаль бюджет учреждениесе
(директор, УКП башлыгы - Аглямов Д.Ф.)

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының социаль һәм агарту эшләре бүлеге башлыгы Н.Н.Латыйповка конкурста җиңүчене һәм призерларны бүләкләү өчен исемлек әзерләргә, смотр-конкурс нәтиҗәләре буенча Актаныш муниципаль районы авыл мәдәният йортлары директорларының гомуми җыелышында фикер алышырга, 2022-2024 елларда Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә эшләмәүче халыкка консультация хезмәтләре күрсәтүне камилләштерү буенча чаралар билгеләргә һәм аларның үтәлешен оештырырга.
3.Смотр-конкурс җиңүчеләрен һәм призерларын Актаныш муниципаль районы гражданлык оборонасы җитәкчесе - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе исеменнән дипломнар белән бүләкләргә.
4. Әлеге боерыкны Актаныш муниципаль районының мәдәният йортлары директорларына җиткерергә.
5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов